ГЛАВА
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.12.2019 Әгерҗе ш. № 95

«Чекалда нефть ятмасын реконструкцияләү. Су ташлауны оештыру» “ТатРИТЭКнефть” ТПП “РИТЭК” ҖЧҖ объектын төзү өчен планлаштыру проекты һәм межалау проекты буенча җәмәгать фикер алышуларын билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 46 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль район Советының 2018 елның 27 июнендәге 28-2 номерлы карары белән расланган җәмәгать тыңлауларын, иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2018 елның 28 декабрендә кабул ителгән 33-2 номерлы «Җәмәгать тыңлауларын, иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» карарына таянып карар итәм:

1. «Чекалда нефть ятмасын реконструкцияләү. Су ташлауны оештыру» “ТатРИТЭКнефть” ТПП “РИТЭК” ҖЧҖ объектын төзү өчен планлаштыру проекты һәм межалау проекты буенча җәмәгать фикер алышуларын билгеләргә.

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, торак – коммуналь хуҗалык, архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеген- җәмәгать фикер алышуларын оештыручы итеп билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. Җәмәгать фикер алышуларын уздыру вакыты – 2019 елның 11 декабреннән 2020 елның 13 гыйнварына кадәр.

2.2. Планлаштыру проектын һәм линияле объектны межалау проектын бастырып чыгару өчен рәсми сайт - http://agryz.tatarstan.ru.

3. Җәмәгать фикер алышуларын оештыручыларга:

3.1. Әлеге карарны 2019 елның 11 декабрендә Әгерҗе муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http://agryz.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru , шулай ук Татарстан

Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының мәгълүмат стендларына урнаштырып бастырып чыгарырга;

3.2. Җәмәгать фикер алышуларының башлануы турында белдерүне Әгерҗе муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http://agryz.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының мәгълүмат стендларына урнаштырырга;

3.3. Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты административ бинасының беренче катында линияле объектны планлаштыру проекты һәм межалау проекты буенча экспозицияне ачарга, шулай ук 2019 елның 11 декабреннән 2020 елның 13 гыйнварына кадәр (8.00 дән 17.00 гә кадәр) экспозиция белән килүчеләрне таныштыру мөмкинлеген тәэмин итәргә.

3.4. 2019 елның 11 декабреннән 2020 елның 13 гыйнварына кадәр чорда идентификация үткән килүчеләрдән, фикер алышына торган проект буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кабул итәргә:

- язма формада: 422230, ТР, Әгерҗе ш., Гагарин ур., 13, каб. № 17 адресы буенча;

- проект экспозицияләренә килүчеләрне исәпкә алу кенәгәсендә язылу юлы белән 422230, ТР, Әгерҗе ш., Гагарин ур., 13, каб. № 17 (8.00 дән 17.00 гә кадәр) адресы буенча.

3.5. Проект буенча фикер алышу нәтиҗәләре буенча җәмәгать фикер алышулары беркетмәсен һәм җәмәгать фикер алышуларының нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә.

3.6. 2020 елның 14 гыйнварында Әгерҗе муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http://agryz.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru җәмәгать фикер алышу нәтиҗәләре турында бәяләмә бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе А. С. Авдеевка йөкләргә.

**В.В. МАКАРОВ**

Башкаручы:
Л.Р. Хазиева